РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ПОСЕЛКА
ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРУССЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
СОВЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 02. 11 2021 г. № 2

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башлыгы урынбасарының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2022 елда үзара салым (бер тапкыр түләү) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” гы 27.10.2021 ел, № 1 карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында” 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 28 октябрендәге 1006 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 28.04.2020 ел, № 5 Карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 09.10.2020 ел, № 7 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» гы Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы башлыгы урынбасарының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2022 елда үзара салым (бер тапкыр

түләү) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”гы 27.10.2021 ел, № 1 карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы
поселогы башлыгы — А. Ә. Шәфигуллин